ТУЙМАС НӘФЕС
Хөкүмәт йортында ришвәтчелеккә каршы көрәш турында сөйләштеләр
> 2

КЫЮ ИЛНАР:
«Чын ир-егет авыр хәлдә илен ташламый!»
> 3



ЗАМАНА ӘЛМӘНДӘРЕ
«Татнефть» ярдәмендә татарның яраткан герое анимация булып кайтты
> 4

ЯЗУЧЫ СҮЗЕ
«Мич тә юк хәзер. Ике әнинең берсе дә юк. Балачак та юк...»
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 66 (29033) | Шимбә | 13 май | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

КЫРЫННЫҢ ТЫНЫЧЛЫГЫ ЮК

Борчыган мәсьәлә

Мошенниклар яшүсмерләрне дә юлдан яздыра башлаган! Хокук сакчылары шулай дип чаң суга. Яшүсмерләрнең бер ише мошенникларга белә торып булышса, икенчеләре җинаятьчеләргә ярдәм итүен башына да китерми. Үсмерләрнең күбесе бу кыек юлга вакытлыча эш эзләгәндә кереп китә, дип кисәтә белгечләр. Баланы мошенниклар тозагыннан ничек сакларга? «ВТ» хәбәрчесе шул сорауга җавап эзләде.

dreamstime.com

Татарстан онлайн рәвештә алданулар иң күп теркәлгән төбәкләрнең беренче өчлегендә кала бирә. Республика халкы дистанцион рәвештә эш итүче кырыгалдарларга атна саен 20 миллион сум акча күчерә. Мошенниклар, гадәттә, үзләре генә эш итми. Шуңа күрә күптән түгел хокук сакчылары аларның арадашчыларын да җинаять җаваплылыгына тарта башлады. Элегрәк курьер булып еш кына таксистлар йөргән булса, соңгы арада алар бу эштән баш тарта башлаган. Шуңа күрә бүген җинаятьчеләр үзләренә ярдәмчене, нигездә, «Телеграм» каналы аша таба икән. Ә бүген аны яше дә, карты да куллана.

Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгыннан хәбәр итүләренчә, мошенникларга ярдәм итүче арадашчылар арасында хәзер яшьләр, хәтта балигъ булмаганнар да очрый башлаган. Аларга, нигездә, курьер буларак эшләргә тәкъдим итәләр икән. Алар, мошенник корбаныннан акчаны алып, аны кырыгалдарга илтеп тапшырырга тиеш була. «Шуңа күрә эш тәкъдим иткән белдерүләрдә нәрсәнедер илтеп биргән, алып кайткан өчен бик зур акча вәгъдә итсәләр, шикләнергә кирәк», – дип кисәтәләр министрлыкта.

Регина ФӘХРИСЛАМОВА, педагог-психолог, балалар психологы:
– Замана балалары тормышта бар нәрсә дә җиңел бирелә дип уйлый. Бер яктан, моңа гаҗәпләнәсе дә юк кебек. Бүген көндәлек тормышыбызда «җиңел акча» дигән төшенчә адым саен очрый, аны гадәти күренеш итеп тәкъдим итәргә тырышалар бит. Бала да шуны күреп үсә. Аннары хәзерге балаларның күбесе начар гамәл кылсаң, аның өчен җәзасы булачагын белмичә үсә. Әйтик, телефонын ватса, югалтса, ата-анасы аңа шундук яңасын алып бирә. Бала нәрсә эшләгәнен аңышмыйча, тиешле нәтиҗәләр ясамыйча да кала. Ул үз хаталарында өйрәнергә тиеш. 9 яшендә инде бала бу кагыйдәне тулысынча аңына сеңдергән булырга тиеш. Аны аңламаган үсмер еш кына мошенник кебек җинаятьчеләр корбанына әверелә дә инде. Әгәр бала кисәк кенә үзгәрсә, үз эченә бикләнсә, тынгысызга әйләнсә, аның белән кара-каршы утырып сөйләшергә, эшнең нидә икәнен аңларга тырышырга кирәк. Кырын эшкә башын тыккан бала еш кына үзен нәкъ менә шулай тота башлый.

Әле узган елның ноябрендә генә хокук сакчылары Казанда җиде яшүсмерне тоткарлаган. 9–11 сыйныфларда укучы бу балалар бер атна эчендә мошенникларга 14 пенсионерны төп башына утыртырга ярдәм иткән. Бу әби-бабайлар уртача 2,3 миллион сум акчасыннан колак каккан. Әле күптән түгел генә шушы юл белән 12 кешене 1,7 миллион сум акчасыннан колак кактырган 17 яшьлек үсмернең эзенә төшкәннәр иде. Ел башында яшүсмерләр арасында интернет аша билгесез кешенең кушуы буенча акчага машиналар яндырып йөрү очраклары да булды.

Март аенда исә Әлмәттә кешеләрне алдап, акча урлауда катнашкан 16 яшьлек үсмер тоткарланды. Ул катнашкан җинаять корбаннары 600 мең сум акчасыннан колак каккан. Ни гаҗәп: дәрәҗәле вузларның берсендә программистка укучы бу егет акчага да мохтаҗ түгел, хәлле гаиләдән. Анысы да бу эшне интернет аша тапкан.

Татарстан Дәүләт идарәсенең цифрлы үсеше, мәгълүмати технологияләр һәм элемтә министрлыгының хокукый тәэмин итү бүлеге җитәкчесе Тимур Ашуралиев фикеренчә, бүген балаларны җәмгыятьтә генә түгел, интернет-киңлектә дә үз-үзеңне дөрес итеп тотарга өйрәтергә кирәк. Моны заман ата-анасының иң төп бурычларының берсе дип саный ул. Мондый белемнәрдән башка аларның мошенник корбанына әвереләсен көт тә тор!

– Бүген олыларның гына түгел, балаларның да социаль челтәрләрдә үз сәхифәсе бар. Шуңа күрә аңа иң беренче чиратта мошенниклар «вата» алмаслык итеп ышанычлы пароль куярга кирәк. Синнән нәрсәдер эшләвеңне сораган сәер смс-хәбәрләргә дә җавап бирергә ярамый. Фотосы гомумән булмый диярлек. Шуңа күрә социаль челтәргә үзең турында артык күп мәгълүмат куярга ярамый. Алар ярдәмендә мошенник корбанын яхшылап өйрәнәчәк, аның ниләр белән кызыксынуын, ниләр яратуын белеп торачак. Шулар ярдәмендә алар соңыннан кешене куркытырга, котыртырга, янарга да мөмкин. Таныш булмаган кеше белән язышкан смсларны да бетереп бармыйча, сакларга кирәк. Таныш булмаган кеше сәер смслар язса, бала бу хакта кичекмәстән ата-анасына хәбәр итәргә тиеш, – ди белгеч.

Таныш булмаган сылтамалар аша күчү дә куркыныч. Мошенниклар кулланган сайтларның адресы язылган юлда, гадәттә, танып булмый торган сәер символлар була, ди Тимур Ашуралиев. Аларын әнә шуннан чамалап була. Белгеч түбәндәге кагыйдәне истә тотарга кирәклеген дә искәртте.

Статистика буенча интернеттагы мәгълүматның 60 процентка якыны ялган, тикшерелмәгән ресурсларда урнаша. Шуңа күрә аны бары тик рәсми чыганаклардан гына карарга кирәк. Ниндидер сылтама аша кереп, онлайн рәвештә әйбер сатып алырга җыенгансыз икән, иң элек аның бәясенә игътибар итәргә кирәк. Әгәр ул артык арзан икән, димәк, сез шикле сайтта утырасыз дигән сүз.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Яңалык

Табибтан калганны кем алыр?

Табибларның эше кимемәгәе әле. Россия Сәламәтлек саклау министрлыгында табиб җилкәсендә булган бурычларның бер өлешен урта медицина персоналына тапшырырга тәкъдим итәләр. Табиблар үзләре риза ди. Әмма калган белгечләр моңа әзерме соң?

«Татар-информ»

Иң элек сан теленә күчик. «Актион Медицина» хезмәте оештырган сораштыруга күз салсаң, урта медицина персоналының 90,6 проценты Сәламәтлек саклау министрлыгы тәкъдимен хупламый. Шәфкать туташларының өстәмә эш алырга теләмәүләре аңлашыла да. Болай да тик торганнары юк (сораштыруда катнашучыларның 63,7 проценты шулай дигән). Кайберәүләре табиб белән шәфкать туташлары арасындагы хәзерге бурычлар бүленеше җитәрлек дәрәҗәдә дигән фикердә (18,9 проценты). Кайсылары ышаныч кимүдән курка: шәфкать туташларына табибка ышанган кебек ышанмаска да мөмкиннәр бит (7,3 процентның фикере).

Ә менә табибларның күпчелеге Сәламәтлек саклау министрлыгы тәкъдимен хуплый (62,3 проценты). 46,2 проценты «табибларны артык эштән күптән азат итәргә кирәк» дигән фикердә тора. 16 проценттан артыгы исә табиб өстендәге бурычларның күпчелеге болай да кече коллегаларына күчкәнен белдергән.

Хәзер инде тәкъдим ителгән инициативаның эчтәлегенә күз салыйк. Бу тәкъдимне Россия Сәламәтлек саклау министрлыгының сәламәтлек саклауны оештыру һәм мәгълүматлаштыру фәнни-тикшеренү институты әзерләгән.

Авторлар участок терапевтыннан урта медицина белеме булган персоналга тапшыру өчен берничә мөһим бурычны алырга тәкъдим итә. Мәсәлән, шәфкать туташларына диспансеризация һәм профилактика буларак медицина тикшерүе узучы кешеләр исемлеген әзерләү, шулай ук халыкка санитар-гигиена сораулары буенча аңлату эшләре үткәрү бурычын бирергә телиләр. Дәвалауга кагылышлы бурычлар да бар:

- медицина тикшеренүен уздыру;
- хроник авырулары булган пациентларның сәламәтлеген диспансер күзәтү;
- медикаментоз һәм медикаментоз булмаган дәвалау ысулларын куллануның нәтиҗәлелеген һәм куркынычсызлыгын бәяләү;
- аз хәрәкәтләнүче сырхауларны өйләренә барып күзәтү;
- «сәламәтлек мәктәпләре»н оештыру һәм үткәрү.

Проект авторлары аңлатуларынча, вазыйфаларны яңадан бүлеп, табибның барлык функцияләрен дә шәфкать туташына тапшырырга җыену түгел бу. Киресенчә, табибка пациент белән эшләргә күбрәк вакыт та калачак, дип өметләнәләр.

Сүзгә-сүз

Дмитрий ЧЕРНЫШЕНКО, Россия вице-премьеры:

Россия – цифрлы хезмәтләр буенча иң алдынгы илләрнең берсе. Ил халкының 85 проценты диярлек интернетка тоташа ала, интернет бәясе ягыннан да бездә иң уңайлы шартлар. Цифрлаштыру программистлар тормышына гына түгел, һәркемнең тормышына үтеп керә. Бу җәһәттән дәүләтнең беренчел бурычларының берсе – белгечләрне укыту, саклау һәм аларга ярдәм итү.

(«Youth RIGF 2023» форумындагы чыгышыннан)

РОССИЯДӘ – ҖӘЙГӘ ӘЗЕРЛЕК

«Росгосстрах Жизнь» иминият компаниясе Россиядә яшәүчеләрдән физик яктан җәйгә ничек әзерләнүләре турында сорашкан.



Күбрәк җитештерелә

Татарстанда хәләл ризык җитештерү өлкәсе үскәннән-үсә. 2019–2022 елларда мондый продуктларны чит илгә сату күләме 20 тапкырдан күбрәккә артып, 300 мең доллардан 6 миллион долларга җиткән. Быел бу күрсәткечне 8 миллион долларга җиткерү күздә тотыла. Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары Рөстәм Гайнуллов әйтүенчә, моның өчен Татарстанда җитештерү линияләре хәләл стандартларга туры китереп үзгәртелә. Хәзер инде яңа проектлар да шушы шартлар буенча эшләнелә.

Министр урынбасары басым ясап әйткәнчә, соңгы елларда Татарстанда хәләл өлкә зур холдингларның да игътибарын җәлеп иткән. Элегрәк исә аның белән асылда кече һәм урта эшмәкәрлек вәкилләре генә шөгыльләнгән.

Татарстаннан хәләл ит, сөт ризыклары һәм тәм-томнар чит илләргә аеруча күп чыгарыла.

Исегезгә төшерәбез: 19–21 майда Казанда хәләл ярминкә узачак. Анда Татарстан һәм Россия җитештерүчеләренең генә түгел, бәлки башка илләрдән китерелгән хәләл ризыклар да тәкъдим ителәчәк.

Табибларга ярдәм

Россия Хөкүмәте киләсе елның 1 гыйнварыннан хәрби табибларга һәм медицина хезмәткәрләренә ярдәм итү программасын гамәлгә кертә. Шулай итеп, гарнизоннардагы медицина оешмаларына эшкә урнашучы табиблар, фельдшер, шәфкать туташларына бер тапкыр 500 мең сумнан 2 миллион сумга кадәр акча бирәчәкләр.

Министрлар Кабинеты матбугат хезмәте хәбәренә караганда, түләү күләме хәрби частьның кайда урнашуына бәйле булачак. Программада медицина вузларын тәмамлап чыгучылар да катнаша ала. Төп шарты – хезмәт килешүен кимендә биш елга төзү.

Ерак Төньяк һәм Арктика төбәкләрендә торак пунктлардан читтә урнашкан хәрби частьлардагы табиблар өчен компенсация күләме 2 миллион сум тәшкил итә. Фельдшерлар һәм шәфкать туташлары өчен – 1әр миллион сум. Ерактагы, юлсыз гарнизоннарның медицина-санитария частьларындагы табибларга – 1,5 миллион сум, фельдшерлар һәм шәфкать туташларына 750шәр мең сум түләнеләчәк. Башка территорияләрдәге торак пунктлардан читтә оештырылган хәрби частьларда эшләүче медицина хезмәткәрләренә килгәндә, табиблар – 1 миллион сум, фельдшерлар һәм шәфкать туташлары 500әр мең сум акча алачак.

Изге Болгар чакыра

40 меңнән артык кунак, пәйгамбәр (с.г.в.) ядкарьләре, күмәк намаз. Изге Болгар җыенында халыкны шактый кызыклы программа көтә. Чара 21 майда узачак.

Татарстанның мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин әйтүенчә, быел халыкка үзенчәлекле күргәзмә тәкъдим ителәчәк: Болгар җиренә пәйгамбәребезнең (с.г.в.) 10 ядкаре кайтартылачак. Бәйрәм программасына килгәндә, чара иртәнге 9 сәгатьтә концерт белән башланачак. Оештыручылар әйтүенчә, быел программа кысасында тагын бер истәлекле датаны – Кол Галинең дөньяга килүенә 840 ел тулуны да искә алачаклар. 11 сәгатьтә Җыенның рәсми ачылыш тантанасы көтелә. Аннан соң Җәмигъ мәчете янында күмәк намаз уку оештырылачак. 10нан 11 сәгатькә кадәр Россия мөселманнары Үзәк Дания нәзарәтенең баш мөфтие Тәлгать Таҗетдин кече манарада тәүбә догасын укыячак.

Көн дәвамында Болгарда халык өчен төрле остаханәләр, күргәзмәләр эшләячәк. Килгән кунаклар билбау көрәше буенча ярыш карый, гарәп каллиграфиясендә язарга өйрәнә, мәдәни программада катнаша алачак.

Әйтергә кирәк, Изге Болгар җыены «KazanForum» халыкара икътисадый форумының бер чарасы булачак. Чарада форумга килгән кунакларны да көтәләр. Гомумән, изге җиргә барлыгы 40 меңләп кеше килер дип фаразлана.

Зыян күрүчеләр арткан

Яз башыннан бирле Татарстанда 2343 кеше, шул исәптән 645 бала (10 майга алынган мәгълүматлар), талпан кадалу сәбәпле, табибларга мөрәҗәгать иткән. Роспотребнадзорның Татарстандагы идарәсе хәбәр иткәнчә, узган елның шушы ук чорындагыга караганда 12 процентка күбрәк сан бу. Республикада талпаннар 3 апрельдән уяна башлаган.

Ведомствода искәртеп үтелгәнчә, 15–26 май чорында һәр көн саен 9.00дән 18.00 сәгатькәчә әлеге бөҗәкләр таратучы инфекцияләрдән саклану мәсьәләләре буенча телефон аша бушлай киңәш-табыш алырга мөмкин. Эш көннәрендә – 8 (843) 238-21-74, ял көннәрендә (9.00 – 17.00 сәгатьтә) 8(843) 238-98-54 телефоны аша шалтыратасы.

Сүз уңаеннан, Татарстанда һәр ел саен 10 меңләп кешегә талпан кадала. Әгерҗе, Актаныш, Әлмәт, Биектау, Саба, Зәй һәм Спас районнарында мондый очраклар аеруча күп теркәлә.

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Изүдән – чәчәк атуга таба

Электән килгән «дәүләт – изү инструменты» дигән билгеләмә бар. Кемдер: «Бүгенге заманда ул сүз хакыйкатькә бик үк туры килми», – дияр бәлки. Чыннан да, булганда да ул, үткән дәверләрдәге кебек, күзгә төртелеп тормый. Тик иленә, җиренә карап, ул бар, яши әле. Теге яки бу илгә төртеп күрсәтеп, кеше, гражданин дәүләт, аның мәнфәгатьләре өчен тотыламы, әллә инде киресенчә, дәүләт үзе гади кеше, аның сыйфатлы яшәеше өченме – шактый төгәл әйтеп биреп була.

Гади кеше мәнфәгатьләре санга сугылсын өчен аның идарә органнары, башкача әйткәндә, дәүләт институтлары нинди булырга тиеш соң? Бүген сөйләшәсе килгән сүз дә нәкъ менә шул институтлар, аларның чыны һәм бик үк чын булмаганнары, хакимият институтлары арасындагы мөнәсәбәтләр, мөнәсәбәттәге үзенчәлекләр хакында иде…

Баштан ук күпчелек илләрдә дәүләт хакимияте институтларының дүртәү булуын да искәртеп китик: закон чыгару органы – парламент, башкарма хакимият булган хөкүмәт, суд системасы һәм дә илбашы – президент. Шушы институтлар, бигрәк тә аларның беренче өчесе хакында сүз барганда «хакимият тармаклары» дигән термин кулланылуы да мәгълүм.

Яши-яши дәүләтләрнең шундый күптармаклы, кем әйтмешли, чатлы-ботаклы хакимият системасына килгәнлеген камиллеккә, нәтиҗәлелеккә омтылу белән аңлатып була кебек. Андый тармаклылык дигәндә, төп хикмәт шул: чынлыкта институтлар бер-берсенә буйсынырга тиеш түгел. Аерым кеше тагын әйтер: «Буйсынмагач, Крылов мәсәлендәге Аккош, Чуртан һәм Кысла рәвешендә калмаслармы соң алар?» – дияр. Калырга мөмкин, тик калырга ярамый. Күптармаклы (институтлы) системаның асылы – һәрдаим үзара килешеп, уртак карарларга килеп эшләүдә, бүгенге модалы сүз белән әйткәндә, консенсус табуда. Президент исә – идеалда калган өч институтка хөкемдар, алар арасындагы мөнәсәбәтләргә, мөнәсәбәтләрнең билгеле бер кысаларда калуына күз-колак булып торучы, шуны гарантияләүче зат.

«Мондый катлаулылык нигә?» дигән сорау туа. Нигә илбашы үзе барысына да баш, барысына да түш түгел? Түгел, чөнки үткән йөзьеллыктан да бигрәк, XXI гасырга караган бүгенге заманда дәүләт идарәсендә субъективлык булмау бик тә мәслихәт. Татарчага тәрҗемә иткәндә бу сүз иң кирәкле карар, кануннарны ниндидер тар даирә түгел, ә бер-берсенә буйсынмаган, киресенчә, үзара оппонент булган көчләр, шул ук сәяси партияләрне дә кертеп, уртак килешүгә килеп кабул итәргә тиешлекне аңлата. Бары шулай. Бары шул чакта гына гаделлек гарантияләнә ала. Бары шул очракта гына сарыклар да исән, бүреләр дә тук кала. Консенсус эшләп торганда гына халык мәнфәгатьләре ныграк, нәтиҗәлерәк яклана. Дөрес икътисадый һәм сәяси курс алына. Ахыр килеп, бар булган үсеш, техник һәм технологик алгарыш, илдәге тормыш сыйфаты да шул факторга барып тоташа, дисәк тә, хаталанмабыз кебек. Ни генә димә, андый корылма, андый система объективлык гарантияли. Ә ул сыйфатның субъективлыктан күпкә яхшырак икәнен беләбез.

Дәүләт институтлары бәйсез булган, камил эшләгән тарафларда илбашы алышыну, бер лидер китеп, икенчесе килү дә шактый җиңел үтәлә. Власть бүлешә алмыйча тарткалашу, гаугалы хәлләр, тетрәнүләргә китерми. Чөнки аның механизмы да инде көйләнгән-җайланган, һәр институт андый этапта үз бурычларын белә һәм үти. Башкарма хакимият сайлауга акча бүлә, аны оештыра, бәйсез суд системасы белән парламент сайлауларның гаделлеген тәэмин итә. Гаделлек дигәндә оппозициянең дә роле зур. Дәүләт институты саналмаган оппозиция өчен сайлау – күп илләрдә хакимият органнарына килү өчен дә реаль мөмкинлек. Хәтсез илләрдә «бүген син – хакимият, иртәгә – оппозиция, бүген – оппозиция, иртәгә – хакимият» принцибы үтәлгәнен беләбез.

Шунысын да әйтик: дәүләт институтлары бәйсез булган тарафларда артык мин-минлекле, мөгез чыгарырга яратучы лидерларны үз урынына утырту рычаглары да булдырылган, эшли. Закон, Конституция беренче урында. Үтәмәдең, боздың – урыныңны бушатырга тиешсең. Шунлыктан ниндидер әтәчрәк сәясәтче дә, лидерлыкка ымсынганда да, килгәч тә, кикриген шиңдерергә, үзен билгеле кысага кертергә, канун кырында калырга мәҗбүр. Калмый, бер генә артык хәрәкәт ясый икән – каурыйларын бик тиз йолкыйлар.

Дәүләт хакимияте институтлары арасындагы мөнәсәбәтләр дигәндә, әгәр дә ки ил, җәмгыять авторитардан котылып җитмәгән яисә формаль рәвештә генә котылган икән, хәл аяныч нәтиҗәләргә килергә, үтә катлауланырга да мөмкин. Күпләр 1993 елның октябрен – Президент Ельцинның ул вакытта Югары Совет дип аталган парламентны танклардан аттыруын хәтерли булыр. Бу – кыргыйлык, сөйләшә, килешә белмәү һәм тилемсәлеккә җиткән мин-минлек нәтиҗәсе. Ә авторитар җәмгыять дигәндә, ул шуның өчен дә авторитар, анда кайсыдыр институт башкалардан өстен. Шул ук суд системасы, шул ук парламент дәүләт лидеры кулы астында, асылын югалтырга мөмкин. Нәтиҗәдә ил еллар буе бер кеше яисә тар төркем фикере, алар акылы белән яшәргә мәҗбүр. Моны субъективлык дими, нәрсә дисең?! Авторитар системада гадәттә фикер төрлелегенә дә урын юк. Андый чакта җәмгыятьтә курку ярала, күпләр, хәтта акыллы, зыялы катлау да дәшми калуны хуп күрә. Мондый хәлдән, үз чиратында, төрле масштаблы бәлаләргә дә берничә генә адым кала.

Дөнья дәүләтләренең абсолют күпчелегендә парламент та, суд системасы да, башкасы да бар. Автократияләр дә аларны асрый. Тик, ни кызганыч, хәтсез очракларда имитация рәвешендә. Тик, мәсәлән, парламент шуның өчен дә парламент, ул һич кенә дә исем өчен генә тотылган бутафор орган була алмый. Суд системасы да бәйсез булганда гына нәтиҗәле…

Язма кайсыдыр аерым бер дәүләткә кагылышлы түгел, гомуми кимәлдә шәрехләнде. Үзебез яшәгән илгә килгәндә, без алда сөйләнелгән бәйсез институтларны булдыру юлында. Андый юл озын, әлегә без сөрлегәабына атлыйбыз, өйрәнәбез. Берничә дистә ел үтүгә, безнең тарафларда да исеме җисеменә йөз процент туры килгән институтлар булыр, эшләп китәр дигән өмет бар.

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

ҺӘР ЭШНЕҢ ДӘ ҖАЕ БАР

tatarstan.ru

Акча өләштең дә бетте түгел, дәүләт ярдәмендә башкарылган эшнең сыйфатын яхшылап тикшерергә кирәк. Коррупциягә каршы тору эшен координацияләү буенча комиссия утырышында Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов шәһәр һәм район башлыкларына әнә шундый киңәш бирде. Чарада Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин да катнашты.

Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, былтыр коррупциягә бәйле хокук бозу очраклары республикадагы икътисадый эшчәнлегенең барлык тармакларында да ачыкланган диярлек. Мәсәлән, дәүләт программаларын тормышка ашырганда, мөлкәт мөнәсәбәтләре, шәһәр төзелеше, юл хуҗалыгы, ритуаль хезмәтләр күрсәтү, дәүләт һәм муниципаль сатып алулар, иминият эшчәнлеге кебек тармакларда ришвәтчелеккә тап булганнар. Узган ел хокук саклаучылар коррупциягә бәйле 1185 җинаять очрагын ачыклаган. Әйтүләренә караганда, Татарстанда ришвәт алу очраклары 18,3 процентка арткан. Былтыр прокуратура вәкилләре коррупциягә бәйле 2903 хокук бозу очрагы турында хәбәр иткән. Нәтиҗәдә судка 72 гариза тапшырганнар, 104 кеше административ җаваплылыкка тартылган. Утырышта хәбәр итүләренчә, фаш ителгән хокук бозу очракларының күбесе керемнәр турында тиешле мәгълүмат җиткермәүгә бәйле. 2022 елда гына да акча янчыгының калынлыгы турында дөресен әйтеп бетермәгән 567 урындагы затны дисциплинар җаваплылыкка тартканнар.

– Бүген теләсә кем ачык чыганакларда «эз» калдыра, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Хокук бозу очракларын ачыклау максатыннан, коррупциягә каршы тору буенча эш аларны анализлауга юнәлдерелгән. Мондый хәлләр массакүләм матбугат чаралары нда киң яңгыраш ала, бу республиканың абруен төшерә, хакимияткә карата ышанычны киметә. Болар барысы да дәүләт хакимияте тарафыннан тиешле бәя бирүне таләп итә. Коррупциягә каршы көрәштә һәрбер дәүләт һәм муниципаль орган катнашырга тиеш.

Хокук бозу очракларын вакытында кисәтеп, булдырмыйча калырга да мөмкин, дип тә искәртте Рөстәм Миңнеханов. Моның өчен тыгыз һәм системалы эшчәнлек булырга тиеш. Рәис Татарстанда тормышка ашырылучы һәм халык арасында зур кызыксыну уяткан «Безнең ишегалды» программасына аерым тукталды.

– Без мондый программа турында күптән хыялландык. Аның кысасында башкарылган эшнең сыйфаты да мөһим. Начар эшлиләр икән, мондый ишегалларын кабул итмәгез. Шәһәр һәм район башлыклары бу эшне шәхсән контрольдә тотарга тиеш. Югыйсә аяныч бит: әлеге программага зур суммалар җәлеп итәбез, ә эшнең сыйфаты түбән. Без бит моның өчен сум белән түлибез, – дип җаваплырак булырга өндәде Рөстәм Миңнеханов.

Рәис район башлыкларын ритуаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендәге эшне тиешенчә оештырмаулары өчен дә шелтәләде. Баксаң, кайбер районнарда мәетне соңгы юлга озату белән шөгыльләнүче оешмалар гомумән дә юк икән. Ә ритуаль хезмәтләрне шәхси компанияләр күрсәтә.

Алга таба авыл хуҗалыгы тармагында да игътибарлырак булырга туры киләчәк. Рөстәм Миңнеханов әлеге тармакта эшләүче оешмалар һәм фермерларга бирелүче грантларны телгә алды.

– Коррупция акчалы җирдә була. Дәүләт авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә грантлар өләшә. Тик акчаны тараттың да бетте түгел, проектлар үтәлешен дә даими күзәтеп барырга кирәк, – диде Рәис.

Барысы да – кешеләр хакына

Илкүләм проектлар илебездә һәм республикада яшәүчеләр хакына гамәлгә ашырыла. Казанда «Бердәм Россия» төбәк бүлегенең илкүләм проектларны тормышка ашыру һәм әлеге эшне яктыртуга ярдәм итү мәсьәләләре буенча комиссиясе утырышында шулай дип белдерелде. Анда «Илкүләм проектлар: Татарстан – 2022» республика бәйгесенә һәм «Обещаю вернутьСя!» проектына йомгак ясалды.

Узган елда республикада илкүләм проектларны тормышка ашыруга 43,7 миллиард сум (шуның 4,9 миллиард сумы – республика бюджетыннан) бирелгән. Татарстан 13 илкүләм проектта, аларга керүче 49 төбәк проектында катнашкан. 2022 елда илкүләм проектларны гамәлгә ашыру кысасында Татарстанда 228 социаль объект төзекләндерелгән.

Быел республика 48 төбәк проектын (барлыгы 29,3 миллиард сумга) гамәлгә ашыруны күздә тота. Фәрит Мөхәммәтшин әйтүенчә, партия проектлары да, шул исәптән «Бердәм Россия»нең Халык программасы да бик кирәкле проектлар булып кала.

Дәүләт Советы Рәисе Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановка, Дәүләт Думасы депутаты, илкүләм проектларны тормышка ашыру һәм әлеге эшне яктыртуга ярдәм итү мәсьәләләре буенча республика комиссиясе җитәкчесе Татьяна Ларионовага, республика Хөкүмәтенә, депутатларга ярдәм күрсәтүләре өчен рәхмәт белдерде.

Илкүләм проектларны тормышка ашыра башлагач ук Татарстанда яшәүчеләрнең әлеге проектларны ничегрәк бәяләвен, беренче чиратта нәрсәләргә игътибар итәргә кирәклеген аңлау мөһим иде. Фәрит Мөхәммәтшин фикеренчә, «Илкүләм проектлар: Татарстан» еллык фотобәйгесе республикада илкүләм проектларны гамәлгә ашыруга җәмәгатьчелек игътибарын җәлеп итү буенча иң уңышлы эш формасының берсенә әйләнде. Узган елда фотоконкурс дүртенче тапкыр үткәрелгән. Муниципаль берәмлекләрдән һәм республика министрлыкларыннан барлыгы 2 мең хезмәт алынган.

Моннан тыш Татарстан «Обещаю вернутьСя!» проектын тормышка ашыручы пилот төбәкләрнең берсенә әйләнгән. Акциягә республиканың асылда барлык районнары һәм Россиянең берничә төбәге кушылган. Махсус хәрби операциядә катнашучы хәрби хезмәткәрләр өчен 15 мең банкадан артыграк кайнатма гуманитар ярдәм штабына җыеп тапшырылган. «Банку обязательно верни!» – өйләренә, һичшиксез, әйләнеп кайтсыннар өчен хәрбиләргә шундый «әмер» бирелә икән.

Әлеге акция йомгаклары буенча, аерым алганда, Бөгелмә, Кукмара, Яңа Чишмә, Алабуга районнары хакимиятләре башлыклары, Казан дәүләт мәдәният институты ректоры Роза Әхмәдиева бүләкләнде.

БЕР КҮРЕШҮ ҖИТӘ

Халык белән аралашырга, ешрак очрашырга кирәк. Әлки районында узган «Бердәм Россия» көнендә әйтелгән төп фикерләрнең берсе әнә шул булды. Чара Дәүләт Советы Рәисе, «Бердәм Россия» партиясенең Татарстан төбәк бүлеге Секретаре Фәрит Мөхәммәтшин катнашында узды.

Бу көнне районда 11 мәйданчык эшләде. Әйтик, «Үзеңнекен сайла» проектын гамәлгә ашыру нәтиҗәләре турында район үзәгендә биш ел элек ачылган «Әлки» кулланучылар кооперативы мисалында фикер алыштылар. Хәзерге вакытта биредә терлек чалу цехы һәм ит ярымфабрикатлары җитештерү цехы эшли. Без цехта булганда хатын-кызлар пилмән ясыйлар иде. Эчлеге яңа суелган иттән ясалганга, пилмән бик тәмле килеп чыга, ди алар. Җитештерүчеләр сүзләренә караганда, продукция мәктәп ашханәләрендә, балалар бакчаларында, кафеларда, шәһәр читендәге балалар сәламәтләндерү лагерьларында зур ихтыяҗ белән файдалана. Кооператив халыктан 86 млн сумлык авыл хуҗалыгы продукциясе һәм чимал сатып алган. «Әлки» кулланучылар җәмгыяте рәисе Агыйдел Турнина сүзләренә караганда, коллективлары да елдан-ел зурая бара.

– Бүген бездә 60ка якын кеше хезмәт куя. Уртача хезмәт хакы айга – 35 мең сум. Кооператив халыкка хезмәт күрсәтү өчен автолавкалар, башка төр автомобильләр сатып алды. Һәр елны эшчәнлегебез киңәя, төрләнә бара. Кафеда һәм кибет аша халыкка бер елда 54 миллион сумлык хезмәт күрсәтелде, – диде ул.

Җәмгыятьнең планнары да зурдан. Колбаса һәм ысланган ит продукциясе цехлары ачып, җитештерүне тагын да киңәйтмәкчеләр. Җитәкчелектән күпмедер ярдәм булса, цех өчен кыйммәтле җиһазлар сатып алырга ниятләре. Ул очракта биредә тагын унлап кешегә эш урыны булыр иде.

Шулай ук, Дәүләт Советы Рәисе Базарлы Матактагы Лисенков исемендәге тарихи-туган якны өйрәнү музее эшчәнлеге белән танышты. Биредә республикада бердәнбер космонавтика музее залы ачылган. Музейга экспонатларны озак вакыт аэрокосмик компания җитәкчесе булып эшләгән Анатолий Михеев тапшырган. Соңгы елларда музейда мәгълүмати технологияләр актив үсеш ала, хәзер инде 13 меңнән артык экспонат цифрлаштырылган.

«Гражданлык сәгате» партия проекты кысасында Фәрит Мөхәммәтшин тематик квиз җиңүчеләрен бүләкләде һәм Әлки районы укучыларына Россия гражданнары паспортын тапшырды. Төп документны 16 яшүсмер алды.

– Сез Әлки районында, безнең күпмилләтле республикада яшәвегез, укуыгыз һәм эшләвегез белән бәхетле. «Без Татарстаннан!» – дип горурланып әйтегез, – диде парламент җитәкчесе укучыларга.

Эшлекле сәфәр кысасында Фәрит Мөхәммәтшин һәм Дәүләт Думасы депутаты Олег Морозов ике улы махсус операциядә катнашучы Туйбикә Сыраеваның да хәлен белештеләр. Хәзерге вакытта Туйбикә ханымның улларының берсе ярадан соң дәвалана икән. Чын патриот уллар тәрбияләгән әнигә депутатлар рәхмәт белдерде һәм егетләрнең тизрәк әйләнеп кайтуларын теләде. Хәрбиләрнең әнисе үз чиратында республика җитәкчелегенә ярдәм һәм аңа күрсәтелгән игътибар өчен рәхмәт әйтте.

Гомумән алганда, районда тормыш гөрли, халыкның да әллә ни зарланырлыгы юк. Басуларда язгы кыр эшләре тәмамланган диярлек. Район башлыгы Александр Никошин быел язның иртә килүен уңай бәяләде. Игенчеләр күңелендә бары бер борчу – әле һаман көткән шифалы яңгырлар юк.

Районның партия активы белән очрашуда Фәрит Мөхәммәтшин чарага йомгак ясады. Үз чыгышында Әлки районы һәм республика алдында торган бурычларны билгеләде.

– Проектның мөһимлеге һәм кирәклеге бүген аеруча сизелә. Безнең бурыч – халыкны берләштерү. «Бердәм Россия» партиясе ил һәм республика җитәкчелеге тарафыннан хупланган сәяси көч буларак, бу мәсьәләне хәл итәргә мөмкинлек бирә, – диде Фәрит Мөхәммәтшин. – Без мондый очрашуларга кызыксыну барлыгын сиздек. Партия активында гына түгел, хакимият вәкилләрендә, җирле совет җитәкчеләрендә, хуҗалык субъектларында да. Безнең өчен халкыбызның милләтара тынычлыгы һәм татулыгы, үсеп килүче буын белән тәрбияви эшне көчәйтүне арттыру мөһим.

Олег Морозов фикеренчә, партиягә идеологик эшне дә көчәйтергә кирәк.

– Партиянең роле сәяси лидерлыкта гына түгел, ә кешеләргә илдәге хәлләрне аңлату, алар белән аралашуда да. Халык аңлый, ләкин аларның бирергә теләгән сораулары бар. «Бердәм Россия» җәмгыятьнең бердәмлеген тәэмин итә. Партия механизмыннан башка без бүген җәмгыятебез алдында торган бурычларны хәл итә алмаячакбыз, – диде Олег Морозов.

Эшләнгән эшләр күп, үтисе бурычлар да җитәрлек. Фәрит Мөхәммәтшин партиянең җирле бүлегенә гражданнар мөрәҗәгатьләре белән активрак эшләргә кушты.

– Без кешеләр белән аз аралашабыз. Ешрак очрашырга, борчыган мәсьәләләр турында фикер алышырга кирәк. Халыктан качарга ярамый, – диде ул.

Ләйсән САФИНА

АГУЛЫЙЛАР, ЯРАМЫЙ...

Белеп тор!

Татарстан урманнарында 10 майга кадәр янгынга каршы махсус режим кертелгән иде. Бу чорда урманга керергә, аның янәшәсендә ут ягарга бөтенләй ярамады. Бу режим тәмамланса да, әле ут белән уйнарга ярый дигән сүз түгел.

vk.com

Россия Гидрометеоүзәге җитәкчесе Роман Вильфанд Татарстанда бишенче класслы янгын куркынычы булырга мөмкинлеген фаразлый. Аның сүзләренчә, Татарстаннан кала тагын 11 төбәктә янгын куркынычы саклана. Ут белән аз гына саксызрак эш иткән очракта да коры һава торышы янгын таралуга сәбәпче булачак. Көннәр җылы тора, әлегә яңгырлар күренми. Татарстан урманчылары гадәттән тыш хәлләргә әзерме?

Республиканың урман-янгын сүндерү үзәге җитәкчесе Айдар Гайфуллин сүзләренә караганда, ут-күздән саклану өчен мөмкинлекләр җитәрлек. Әмма бер теләк: ут кына чыкмасын!

– Бездә төрле типтагы 25 урман-янгын сүндерү станциясе бар. Алар республиканың төрле районнарында урнашкан. Янгынга каршы торуга күздән әзерләнә башлыйбыз. Ут урманга кермәсен өчен махсус полосалар ясыйбыз. Кыскасы, җиң сызганып әзер торабыз. Урманчылар янгын куркынычы булганда, көн-төн кизүдә. Җәяү дә күзәтәбез, күктән дә карыйбыз, махсус техникалар белән дә урман эчләренә рейд ясап торабыз, – ди ул.

Урманчы янгынны сүндерүнең төрләрен дә әйтте. Гадәттә без су сипкәнне генә күрсәк, утны ут яндырып та туктатып була икән. Бер-берсенә каршы килгән ялкын, очрашкач, сүнә, ди Айдар Гайфуллин.

– Соңгы вакыйгалар янгынның никадәр аяусыз икәнен күрсәтте. Берүк сак булыйк. Инде кат-кат әйтеп торабыз: янгын үзеннән-үзе генә чыкмый, күп очракта моңа кеше гаепле, – ди урманчы.

Урманга керми тору дигәннән, республикада урманнарга керү тагын өч атнага тыела. 21 көн дәвамында урманнарда җәяү йөрү генә түгел, анда транспортта йөрү дә тыелачак. Сәбәбе – кайбер районнарда агачларны ефәк күбәләгеннән эшкәртәләр.

Татарстанның урман хуҗалыгы министры беренче урынбасары Илгизәр Зарипов сүзләренчә, зыян салучы бөҗәкләрне агулап бетергәнче урманга керергә ярамый.

– Татарстанның 53 мең гектар урманында агулау эшләре алып барыла. Без ефәк күбәләгенә каршы биологик препарат белән эшкәртәбез. Аның кешеләргә дә, бал кортларына да зыяны аз. Әмма саклану кирәк, – ди Илгизәр Зарипов. – Эшкәртелә торган участок чикләреннән 300 метр ераклыкта кисәтү аншлаглары урнаштырылды. Өч атналык чикләү Азнакай, Аксубай, Актаныш, Алексеевск, Әлки, Минзәлә, Мөслим, Яңа Чишмә, Нурлат, Сарман, Чирмешән һәм Чистай урманчылыклары территориясендә гамәлдә булачак.

Урманнарга керү чикләнгән чорда «Урман янгын сүндерү үзәге»ндә Татарстан халкын борчыган барлык сорауларга да җавап бирергә әзерләр. Биредә бердәм контакт-үзәк эшләячәк. 8(843) 221 37 95 номерына шалтыратып, үзегезгә кирәкле мәгълүматны алып булачак.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

БЕР МАНДАТЛЫ САЙЛАУ ОКРУГЫ БУЕНЧА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫНА ӨСТӘМӘ САЙЛАУГА ТЕРКӘЛГӘН КАНДИДАТЛАРНЫҢ САЙЛАУ АЛДЫ АГИТАЦИЯСЕ МАТЕРИАЛЛАРЫ

МАТЕРИАЛЛАР АВТОР ӘШКӘРТҮЕНДӘ БАСТЫРЫЛА. АЛАРНЫ ГАЗЕТА БИТЛӘРЕНДӘ УРНАШТЫРУ БАСМА МӘЙДАН БҮЛҮ БУЕНЧА ҮТКӘРЕЛГӘН ЖИРӘБӘ НӘТИҖӘЛӘРЕНӘ ТУРЫ КИЛӘ

№ 20 Электротехник бер мандатлы сайлау округы

Теркәлгән кандидат Вахитов А.Р.
Агитация материалы. Татарстан Сайлау кодексының 62 маддәсе нигезендә бушлай бастырыла.

№ 20 Электротехник бер мандатлы сайлау округы

Теркәлгән кандидат Нигъмәтуллин Р.Р.
Агитация материалы. Татарстан Сайлау кодексының 62 маддәсе нигезендә бушлай бастырыла.

ЫШАНЫЧ

КУРКУ ХИСЕН НИЧЕК ҖИҢӘРГӘ?

Ватан хакына

Ун елдан артык контракт буенча хәрби хезмәт узучы, хәзерге вакытта да Ватан алдындагы бурычын үтәүче Илнар Галиев фикерләре.

МАХСУС ХӘРБИ ОПЕРАЦИЯДӘ КАТНАШУЫ ТУРЫНДА:
– Бу мәсьәләдә артык фикер алышып торасы да юк. Без Ватан алдындагы бурычыбызны үтибез. Ә туган җиреңне ярату хисен балаларда кечкенәдән үк гаиләдә, өйдә тәрбияләргә кирәк. Бу хакта мәктәптә дә онытырга ярамый. Аерым алганда, тарих фәнен ныклап өйрәтсеннәр. Чөнки үткәнен, тарихын белгән кеше һичшиксез үз иле белән горурланып яшәячәк. Ватанпәрвәрлек хисен тәрбияләүдә спорт та мөһим урын алып тора, минемчә. Кечкенәдән үк спорт белән шөгыльләнү кешенең холкын ныгыта гына. Ә чын ир-егет авыр хәлдә илен ташламый.

КУРКУ ХИСЕ ТУРЫНДА:
– Курку хисе һәркемдә бар инде ул. Аны җиңә белергә кирәк. Минемчә, үлемнән, гомумән дә, куркырга кирәкми. Кемнең кайда гомере өзеләсе билгесез. Мин махсус хәрби операциядә курыкмыйм. Чөнки хәрби иптәшләремә ышанам. Курку хисен җиңәргә әнә шул ярдәм итә. Монда һәркем ныклы хәрби әзерлек уза. Башта солдатларга шәхси әзерлек курслары үткәрәләр, аннары хәрби хезмәт өчен кирәкле төп юнәлешләр буенча барлык күнекмәләрне ныклап өйрәнәсең, шуннан соң отделение, взвод, рота, батальон составында әзерлекне алга таба дәвам иттерәсең. Һәркем үз бурычын белгән һәм тиешенчә үтәгән хәрби бүлекчәләрдә һөҗүм итү барышында югалтулар юк дәрәҗәсендә була. Бердәнбер җиңелүне белмәгән полководец Суворов бик дөрес әйткән: өйрәнгәндә авыр булса, сугышта җиңел булыр.

САКЛЫК ЧАРАЛАРЫ ТУРЫНДА:
– Иң беренче чиратта, хәрбиләр физик яктан әзер булырга тиеш, минемчә. Булачак хәрбинең беләге никадәр көчлерәк булса, аңа үз бурычын үтәргә шулкадәр җиңелрәк булачак. Икенчедән, өс-башка акчаны кызганырга ярамый. «Спецназ»да хезмәт итүчеләрнең бер әйтеме бар: яхшы сугыш кирәк-яраклары – бәһасез. Моның белән килешмичә мөмкин түгел.

ӨЙДӘГЕЛӘРНЕҢ КӘЕФЕ ТУРЫНДА:
– Ир-ат – гаиләнең төп сакчысы. Ватан исә менә шул гаилә, туган йорт, аерым бер авыл, шәһәрдән башлана да инде. Шуны истә тотарга кирәк. Мин бармасам, минем балаларым, әти-әнием, туган йортымны кем саклаячак соң? Өйдәгеләр әнә шуны аңласын иде. Ватан алдындагы бурычын үтәргә теләк белдергән ир-атка мөмкин кадәр ярдәм итсеннәр. Безгә шалтыратсыннар, хатлар язсыннар. Шуны да әйтәсем килә: интернетта, телеграм-каналларда җыен кирәкмәгән, тикшерелмәгән мәгълүмат укып ятмасагыз иде. Чөнки еш кына ялган хәбәрләрне махсус рәвештә халыкны хафага төшерү өчен тараталар. Ирең, әтиең, улың, абыең шалтыратып җиткергән хәбәрдән дә яхшысы юк.

Эльвира ВӘЛИЕВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Республикада спорт көрәшен популярлаштыруга зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен Н.А. Зеленов исемендәге «Шинник» спорт комплексы» хосусый учреждениесенең спорт корылмалары инструкторы, «Түбән Кама муниципаль районының Татар-башкорт милли спорт көрәше федерациясе» иҗтимагый оешмасы советы башкарма директоры **Әхмәдиев** Габбас Госман улы **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

* * *

«Минзәлә районының коммуналь челтәрләре» акционер җәмгыяте генераль директоры **Габдрахманов** Рәсим Кави улына, «Каты көнкүреш калдыклары полигоны» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Галимова** Гөлнара Инсаф кызына, «Буа-Водоканал» акционер җәмгыятенең юынтык суларны агызу участогы башлыгы **Галимов** Илнур Илдар улына, «Сууткәргеч-канализация һәм энергетика хуҗалыгы» акционер җәмгыятенең канализация челтәрләрен эксплуатацияләү цехы авариядән соң торгызу эшләре слесаре (Түбән Кама шәһәре) **Кадыйров** Мансур Нургаяз улына, РСК «ПАК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Трифонов** Сергей Николаевичка, «Татарстан Республикасы техник инвентаризация һәм кадастр эшләре бюросы» акционер җәмгыяте генераль директоры урынбасары **Хәйруллина** Ольга Владимировнага **«Татарстан Республикасының атказанган торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының төзелеш технологияләре бүлеге башлыгы **Модина** Оксана Викторовнага, «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстан юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең сыйфатны контрольдә тоту һәм эшләрне кабул итү бүлеге башлыгы урынбасары **Фәрдиев** Камил Наил улына **«Татарстан Республикасының атказанган төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Казан шәһәренең «Чаңгы ярышлары һәм спорт ориентлашуы буенча спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе тренеры **Кулагин** Анатолий Михайловичка, Чаллы шәһәренең «Титан» спорт мәктәбе» муниципаль автоном учреждениесе тренеры **Лгач** Надежда Николаевнага, Чаллы шәһәренең «Титан» спорт мәктәбе» муниципаль автоном учреждениесе тренеры **Лгач** Николай Николаевичка, Чаллы шәһәренең «Титан» спорт мәктәбе» муниципаль автоном учреждениесе тренеры **Шеблов** Геннадий Михайловичка **«Татарстан Республикасының атказанган физик культура хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Тәтеш район дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесенең ветеринария-санитария эксперты **Алмазова** Галина Алексеевнага, «Чистай район дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесенең 1 номерлы ветеринария-санитария экспертизасы лабораториясе мөдире – ветеринария табибы **Петрова** Любовь Пантелеймоновнага **«Татарстан Республикасының атказанган ветеринария табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Лаеш балык заводы» ябык акционер җәмгыятенең Ташкирмән балыкчылык участогы кабул итү-тапшыручысы **Кузнецова** Евдокия Васильевнага, «ЧАЛЛЫ ИКМӘГЕ» акционер җәмгыяте кондитеры **Төхфәтуллина** Нурсинә Наил кызына **«Татарстан Республикасының атказанган азык-төлек сәнәгате хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Олы Кариле» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте агрономы (Татарстан Республикасының Кама Тамагы районы) **Шәйхетдинов** Мансур Гали улына **«Татарстан Республикасының атказанган агрономы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Әюпов Рамил Миргалим улы» крестьян (фермер) хуҗалыгы механизаторы (Татарстан Республикасының Мөслим районы) **Гыймаев** Фәнис Габделхәй улына, «Сөләйманов Әхтәм Исмәгыйль улы» крестьян (фермер) хуҗалыгының Фомкино бүлекчәсе тракторчысы (Татарстан Республикасының Нурлат районы) **Мөхәммәтшин** Хәлим Хәсән улына, «Урал» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте механизаторы (Татарстан Республикасының Кукмара районы) **Хисматуллин** Мансур Бикмулла улына **«Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы»** дигән мактаулы исем бирелде.

БИШТӘН ӨЧКӘ МЕНӘСЕ

2021 ел нәтиҗәләре буенча илкүләм фәнни-технологик үсеш рейтингында республика – бишенче урында (192,2 балл). Татарстан Фәннәр академиясендә узган Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты каршындагы Эксперт советының күчмә утырышында әлеге исемлекне яхшырту мәсьәләсе дә каралды.

Утырышта Татарстанның фәнни-технологик үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру, тикшеренү оешмалары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру юллары, «фән – технологияләр – инновацияләр» социаль институтының бердәм комплексын төзү, шулай ук фундаменталь тикшерүләрне үстерү турында да фикер алыштылар.

Эксперт советы рәисе Роза Әхмәдиева билгеләп үткәнчә, хәзерге вакытта Татарстан Россиянең фәнни-технологик үсеш дәрәҗәсе буенча алдынгы төбәкләр унлыгына керә. Республика «Приоритет 2030» федераль программасын тормышка ашыруда актив катнаша. Татарстанда галимнәр, тикшеренүчеләр, студентлар куәтен инновацион эшчәнлектә тормышка ашыру өчен мөмкинлекләр зур.

Татарстанның цифрлы үсешенә ярдәм итү ассоциациясе рәисе Рифкать Миңнеханов чыгышында Татарстанның исемлектә лаеклы бишенче урында булуын билгеләп үтте. Фәнни-технологик үсеш өчен хокукый нигезләрнең һәм инфраструктураның булуы, фундаменталь тикшеренүләр белән шөгыльләнүче студентлар саны белән, шулай ук тикшеренүләрне финанслау буенча да республиканың башка төбәкләрдән аерылып торуын әйтте. Шул ук вакытта фәнни-тикшеренү үзәкләре һәм сәнәгать предприятиеләре җитәкчеләрен инновацион эшчәнлекне киңәйтү белән активрак шөгыльләнергә чакырды. Ни өчен дигәндә, алдагы елларда беренче өчлеккә эләгәсебез бар.

2021 елдагы урын	Төбәкләр	Баллар
1	Мәскәү	212,4
2	Санкт-Петербург	205,5
3	Томск	204,5
4	Башкортстан	202,7
5	**Татарстан**	**192,2**



Татарстан Рәисе ярдәмчесе Альберт Гыйльметдиновтан әлеге илкүләм исемлеккә карата фикерен сораштык.

– Без алдагы урыннар белән канәгать, ә арттагысы белән юк. Аларны яхшырту өчен бурыч куябыз. Өченче урынга күтәрелергә кирәк. Безнеңчә, республика Мәскәү, Санкт-Петербургтан соң өченче урында булырга тиеш, – диде ул.

Аның фикеренчә, мондый рейтинглар булдыру кирәк. Тик аның кимчелекле яклары да бар. Әйтик, исемлектә фәнни тикшеренү институтларындагы эшләгән галимнәрнең фәнни дәрәҗәсен генә исәпләгәннәр. «Университетларда алар бик күп. Бөтен кандидат, докторлар шунда. Әмма алар исемлеккә кермәгән. Янәсе, алар укыта. Чынбарлыкта алар фәнни эшчәнлек тә алып бара. Бу дөрес нәрсә түгел», – диде ул.

Татарстан мәгариф һәм фән министрының беренче урынбасары Андрей Поминов фән һәм технологияләр өлкәсендәге җитди проблемаларга тукталды. Аның әйтүенчә, республика фән картасы начар килешенгән һәм бу тикшеренүләрдә өстенлекле темаларның булмавын күрсәтә. Югары уку йортларындагы тикшеренүләр өлкәсенә инвестицияләүне арттыру бурычына җавап бирми торган модельләр дә бар. Шуңа күрә фәнни-технологик үсеш программасын дөрес гамәлгә ашыру, тикшерү оешмаларының федераль проектларда актив катнашуы да кирәк.

Сәрия МИФТАХОВА

«Татар-информ»

Премьера

Ата һәм бала. Тамырларында бер үк кан аккан бу ике затның арасын тормыш-яшәештәге үзгәрешләр дә, идеаллар да, башкасы да ерагайта ала. Әмма нигезләрен онытырга бирсенең дә хакы юк. Әмирхан Еники әсәрләре буенча төшерелгән «823 километр» нәфис фильмы тагын бер кат әнә шул хакыйкатьне искә төшерде.

НИГЕЗ

«823 КИЛОМЕТР» ФИЛЬМЫ НӘРСӘ ТУРЫНДА?

Узган ел төшерелә башлап, яңарак кына тәмам булган әлеге фильмны Казанның «Мир» кинотеатрында тар җәмәгатьчелеккә тәкъдим иттеләр. Кызганыч, аны тагын кайда һәм кайчан карап булачагын әйтә алмыйбыз. Фильмның продюсеры Миләүшә Айтуганова сүзләре белән әйтсәк, аның әле кинофестивальләрдән әйләнеп кайтасы бар.

Фильм нәрсә хакында соң? Бу сорауга һәркем үзе җавап бирергә тиеш кебек. Режиссерларның берсе Әмир Галиәскаров фильмның нигезе итеп аталар һәм балалар проблемасы алынуын әйткән иде. Аның бу сүзләрен төп геройның улына язган соңгы хаты да раслый. Анда түбәндәге юллар бар:

«Мин – бер чор, син – икенче чор кешесе, дигәндәй. Идеаллар да башка. Адаша күрмә бу дөньяда, улым. Тамырыңны, кайдан икәнеңне, нәселеңне онытма! Минем хаталарны кабатлама. Яраткан кешеләрең белән араңны өзмә. Мин менә ялгыштым, шуңа үкенеп бетә алмыйм…»

Әмма «823 километр»да Әмирхан Еникинең өч төрле әсәре файдаланыла. Ә аларның һәркайсы буенча аерым фильм төшерергә булыр иде, мөгаен. Шуңа, фильмга ул әсәрләрнең кечкенә өлешләре генә кертелсә дә,

ФИЛЬМ ТУРЫНДА КЫСКАЧА БЕЛЕШМӘ
- «823 километр» нәфис фильмының сценарий авторы – Валерия Байкиева. Режиссерлар – Ирек Хафизов, Әмир Галиәскаров.
- Әлеге кинокартина мәшһүр классигыбыз Әмирхан Еникиның өч әсәрен – «Матурлык», «Кем җырлады?» һәм «Бер генә сәгатькә» новеллаларын берләштерә.
- Рольләрне Илдар Хәйруллин, Алсу Гайнуллина, Илдус Әхмәтҗанов, Әлфия Хәсәнова, Гөлчәчәк Хафизова, Резеда Сәлахова һәм башкалар башкара.

«823 километр»да башка темалар һәм башка проблемалар да очраша, дияргә мөмкин.

Еники сүзе

Фильмның кайбер өлешләре Татарстан Кинематографистлары берлеге рәисе Илдар Ягъфәровның да күңеленә тигән.

– Экранны алдап булмый: ул фальшны да, чын хисләрне дә яхшы күрә. Күңелемә тигән мизгелләр дә булды. Экрандагы әтине үземнең әти кебек кабул иттем, чөнки безнең арада да шундыйрак мөнәсәбәтләр булды. Берике өлешендә зал да елады. Ягъни фильмда хәрәкәт гел юк түгел. Әмма әйтеп бетерелмәгән сүзләр, паузалар күп. Кайсыбер фильмнарда уңышлы алым ул, әмма бу очракта түгел. Буш диалоглар да шактый. Аларны без радиоспектакль дип атыйбыз. Билгеле, һәр яңа татарча фильм – безнең өчен зур вакыйга, бәйрәм. Әмма бүген тәнкыйть сүзләре яңгырарга тиеш, чөнки шуннан башка без үсә алмыйбыз. Ә безгә үсәргә кирәк, – диде ул.

Драматург Мансур Гыйләҗев, беренче эш итеп, сценаристның эшен бәяләде.

– Зур эш башкарылган. Иң мөһиме – монда Әмирхан Еникиның мохите сакланган, ә бу – бик зур нәрсә. Сценаристның роле зур, ул Әмирхан Еники әсәрләрендәге вакыйгаларны хәзерге көнгә яраклаштырган. Без аларга бүгенге күзлектән карыйбыз, аваздашлык тапкач, тирәнрәк аңлый башлыйбыз, – дип, кинокартинаның уңай якларын санады ул. Ә кимчелекләргә килгәндә… – Әмирхан аганың тәэсире зур булган, күрәсең: проза формасы артыграк киткән. Кино формасына хас динамика, конфликт җитеп бетмәде. Шулай булуына карамастан, фестивальләрдә дә җиңәргә лаеклы фильм килеп чыккан.

Проза формасы, димәктән, чыннан да, геройлар арасындагы диалоглар урыны-урыны белән гайре табигый тоелды. Фильмнан бигрәк, әдәби әсәрнең аудиоверсиясен хәтерләткән мизгелләр бар иде. Иҗат төркеме моны, Әмирхан Еникиның телен җиткерәсебез килде, дип аңлатты. Филология фәннәре кандидаты, Әмирхан Еники иҗаты белгече, фильм өчен язылган сценарийны татар теленә тәрҗемә итүче Гөлфия Гайнуллина болай диде: «Сценарийның кайбер өлешләренә Әмирхан Еникиның сүзләрен дә кертеп урнаштыруны кирәк санадым». Билгеле, фильмны әдипнең кабатланмас теленә «төреп» бирү – яхшы алым, ләкин кино сәнгатенең үз таләпләре бар бит. Бу очракта да, режиссерлар аз гына күбрәк тырышса, алтын урталыкка ирешеп булыр иде.

Тагын бер нәрсә: башка татар фильмнарындагы кебек, монда да театр артистлары уйный. Билгеле, кино өлкәсендә тәҗрибә тупларга өйрәнгәннәре фильм белән спектакльнең аермасын яхшы тоемлый. Менә шундый киноактерлар күбрәк булсын иде бездә. Ә без һаман акча, бюджет турында сөйләшәбез…

Фильм турында фикер алышуда геройларга кагылышлы фикерләр дә яңгырады. Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла фикеренчә, төп геройның улы, әйтик, Мостай Кәримнең оныгы Тимербулат Кәримов шикеллерәк зур кеше булса, әти – ул арасындагы конфликт кызыклырак килеп чыккан булыр иде. Сүз уңаеннан, Ркаил әфәнде үзе дә бу фильмда катнаша. Аның кем ролен башкаруы сер булып калсын.

– Әдәбиятны яраткан, татар язмышы өчен борчылган кешеләр өчен яхшы гына фильм килеп чыккан. Монда тел мәсьәләсе дә, туган нигез, тамырларны оныту проблемасы да күтәрелгән. Әмма әти белән ул арасындагы конфликтка кискенлек җитеп бетмәде. Әти кеше – язучы. Ә без, язучылар, ниндидер матди продукт чыгара торган кешеләр түгел. Монда әти дә, аның улы да шактый уңышларга ирешкән кешеләр буларак сурәтләнгән. Фильмда язучының улын, әйтик, Мостай Кәримнең оныгы кебек олигарх итеп сурәтләргә була иде. Ә ул – клиплар төшерүче. Ваграк кеше ягъни. Баерак кеше булса, конфликт кызыклырак булыр иде, – диде ул.

Фикер

Әмирхан Еникиның кызы Флера КАРТАШЕВА:

– Тагын бер мәртәбә әтинең хәтерен яңартуыгыз өчен бик зур рәхмәт сезгә! Фильм яхшы килеп чыккан, әмма бер кимчелеге турында әйтмичә булдыра алмыйм. «Матурлык» әсәрендәге геройлар – кечкенә малайлар түгел, ә студент яшенә җитеп килүче егетләр (фильмда бу рольләрне кечкенә малайлар башкара. – **Авт.**). Гыйлемдар, Бәдретдиннең әнисен күргәч, башта тәмам куркып кала. Соңыннан исә скрипка тавышы, моңлы көй, мәхәббәт тулы күзләре белән бер-берсенә караган ана һәм улны күрә дә, аңа Бәдретдиннең әнисе кисәк кенә яктырып киткән кебек тоела башлый. Ул чын матурлыкның ни икәнен аңлый. Ә фильмда бу мөһим күренеш булмады, менә шул җитмәде миңа…

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Язучы сүзе

Марат КӘБИРОВ

Чүлмәк

Моң кайвакыт чүлмәктән дә чыга икән. Кечкенә чуен чүлмәк ул, төбе учка сыярлык кына. Иске сарайны сүткәндә, идән сайгаклары астыннан килеп чыкты да сискәнеп куйдым. Бала чагым белән очрашкан шикелле тоелды.

Ник икәнен сораганым булмады, мин әнине – «әни», дәү әниемне «әнкәй» дип йөртә идем. Кечкенәдән шулай өйрәткәннәр инде. Бу шулкадәр табигый, бөтен кешенеке дә шулай булырга тиештер шикелле тоела иде бугай. Үзем белән бергә уйнаган малайларның кайберсеннән: «Ә синең әнкәең кайда?» – дип сораштырганым әле дә истә. Һәм аларның җавабын ишеткәч: «Кара әле, ул әнкәен «әби» дип йөртә!» – дип аптыраганымны да хәтерлим.

Әнинең яшь, көчле чагы булгач, бөтен гомере эштә үтә. Ул фермада эшли, аннан кайта да урманга китә. Я утын әзерли, я печән чаба. Ул заманнарда колхоз сарыкларына туйра, кычыткан, печән әзерләү дә бар. Кайчагында малчыларга да чөгендер кишәрлеге бүлеп бирәләр. Урманчылык та әледән-әле эшкә чакырып тора, агач утыртырга, миллек-себерке бәйләргә, печән чабарга куша, хәтта имән чикләвеге белән каен бөресе дә җыйдырталар. Тагын әллә нәрсәләр килеп чыга… Бер сүз белән әйткәндә, иртә яздан кара көзгә кадәр эш бетми торган иде. Шуңа мин гел әнкәй карамагында калам. Ә баланың баласы балдан да татлырак була. Һәм мин әнә шундый балдан татлы кеше булып гомер итәм.

Әни дә ярата инде, район үзәгенә барган саен, кәнфит-печенье ише тәм-том төяп кайта. Бергәләп чәй эчәбез дә, ул тәм-томны «кунак килсә» дип шкафка алып куялар. Бөтен малайларның да мондый тәм-томын яшереп тоталар, алар өйдә кеше юк чакта эзләп тә карый, тапсалар, мул гына өлешен урлап, икенче җиргә яшерәләр. Мин төгәл беләм инде, шулай итмәгән бер генә малай да юк. Кайберләренә үзем дә эзләшкән бар. Тапкан гына юк. Ә минеке һәрчак иректә.

Киногa барасы булса да акча сорап этләнәсе түгел. Биш тиенлекләрнең кайда икәнен мин беләм. Анда әллә ничә тапкыр кино карарлык, әллә күпме перәннек алырлык, әллә ничә «кильки» консервасына җитәрлек акча бар. Җитмәсә, әнидән дә, әнкәйдән дә сорап алырга була. Мин хәтта әнинең хезмәт хакы һәм әнкәйнең пенсиясе кайда икәнен дә беләм. Тотып, чутлап та караганым бар. Тигәнем генә юк. Аларына тияргә ярамый. Кирәкми дә инде. Бөтен нәрсә үз ихтыярында булгач, урлашасы киләмени?

Ләкин малайларны иң кызыктырган нәрсә чүлмәк иде. Кайчан гына килеп керсәк тә, анда һәрвакыт ниндидер тәмле әйбер пешә. Я каз өйрәсе, я пылау, я бәлеш. Ит, бәрәңге, кишер, суган кебек нәрсәләр салып, чүлмәктә пешкән ризыкны бездә чүлмәк бәлеше дип йөртәләр. Төрлесе була инде. Һәм алар һәрвакыт тәмле була. Ул чорда халык мал асраса да, ит бик иркен булмый торган иде. Итле ризыкны кунак килгәндә, көтүче кайтканда, утын-печән китерткәндә генә пешерәләр. Анда да саллырак калҗаларны «кеше алдына», өлкәннәр табынына куялар, бала-чагага калдык-постыгы гына эләгә. Шуңа да безгә бик тәмле тоелгандыр инде. Без рәхмәт әйтәбез, ризыкны мактап туя алмыйбыз. Өстәвенә әнкәй дә, малайларның мактавына җавап итеп:

– Тылсымлы чүлмәк бу, балам, – дип, серле елмая, – мичкә генә куясың да, үзе пешерә.

«Тылсымлы» дигән сүзне ишеткәч, хәтта минем дә күз маңгайга менә. Югыйсә әнкәйнең ашарга әзерләгәнен дә күргәнем бар бит инде. «Чынлап та шулайдыр ул, югыйсә һәрвакыт тәмле булмас иде», – дип уйлыйм. Ә малайлар көнләшә. Кайберләре: «Берәр көнгә генә биреп тор әле», – дип сорый. «Безнең мичтә генә пешерә ала ул, читкә китсә, тылсымы югала», – дип алдашам мин. Саранлык та бар инде бераз, чынлап шулайдыр кебек тә тоела. Ә бер мәлне чүлмәк юкка чыкты. «Шушында гына куйган кебек идем бит, әй, бу хәтернең юклыгы», – дип зарланып йөрде әнкәй. «Син тимәдеңме, берәрсенә биреп җибәрмәдеңме?» – дип тә сорады. Әрләмәде алай. Бер-ике көннән дус малай «табып бирде». Ул алып киткән булган икән. «Бездә чынлап та эшләми, – дип зарланды соңыннан. – Әллә ничә тапкыр мичкә тыгып карадым. Берни дә пешермәде». «Аның серен әнкәй генә белә», – дип сөендем мин. Ә чүлмәк кабат тылсымлыга әйләнде, безне татлы ризыклар белән сыйлап торды.

Бер мәлне без үсә төштек, офыклар киңәйде, дөньяда ризыктан да татлырак нәрсәләр барлыгы ачыкланды. Әнкәй дә олыгайды. Теге чүлмәкнең дә тылсымы беткән кебек булды, ә көннәрнең берендә ул бөтенләй юкка чыкты, онытылды, хәтта булмагандыр да шикелле тоела башлады. Әгәр сарайны сүткәндә килеп чыкмаса, мин аның барлыгын да искә төшерә алмас идемдер.

Ниндидер җайлы урынга туры килгән ул. Шул чактагы кебек сакланган. Хет хәзер мичкә кертеп утыртсаң да нәрсәдер пешереп бирер шикелле. Тик алай булмас шул инде. Мич тә юк хәзер. Әнкәй дә, әни дә юк. Ике әнинең берсе дә юк. Балачак та юк. Чүлмәк кенә бар, ул гына тылсымын югалтмаган бугай. Аның эчендә татлы сагыш кайный кебек. Якты парлары татлы моң булып күңелгә тула. Никадәр кадерле балалар булганбыз бит әни-әбиләребез, әти-бабайларыбыз өчен. Аларның мәхәббәте гади генә чүлмәкне дә тылсымга әйләндергән. Ризыкларыбызны – татлы, тормышыбызны якты иткән. Бәлки, сабый чакта җаныбызда яралган шул рәхмәт хисе күңелләребезне бүген дә яктыртып яшидер.

Бар дөньямны онытып, шул чүлмәкне тотып басып торам. Бераздан ул чылана башлый. Тып-тып… тып… тып… Яңгыр тамчылары бугай ла ул… Балачактан килеп яуган яңгыр…

БЕЗНЕҢ ЗАМАН ӘЛМӘНДӘРЕ

ӘҖӘЛНЕ АЛДЫЙ АЛГАН ЛЕГЕНДАР КАРТНЫ «ТАТНЕФТЬ» ХАЛЫККА КАЙТАРДЫ

Күк канцеляриясендә гадәттән тыш хәл: Әлдермеш авылында Әлмәндәр исемле карт рөхсәтсез озак яши икән! «Өстәге»ләр белгәнче, аның җанын алырга дип, Җиргә 1550 номерлы агентны җибәрәләр. Шуннан… Таныш сюжетмы? Танылган драматург Туфан Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» пьесасындагы үлемсез герое яңадан сәхнәгә кайтты! Бу юлы – өлкәннәр дә, балалар да рәхәтләнеп карый алырлык мультфильм рәвешендә.

Хыялланудан башлана

Туфан Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» әсәренә нигезләнгән әлеге мультфильм татарча беренче тулы метражлы анимацион фильм санала. Бу проект Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов һәм ТР Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе, «Татнефть» компаниясе матди ярдәме белән булдырылды. 10 майда иҗат эшен халыкка Камал театрының Зур сәхнәсендә тәкъдим иттеләр. Димәк, дистә елдан соң Әлмәндәр карт кабат туган сәхнәсенә кайтты!

Хыялдан чынбарлыкка адым ясарга булышкан, легендар геройны экранга чыгаруда ярдәм иткән кешеләргә «Әлдермештән Әлмәндәр» анимацион фильмының сәнгать җитәкчесе, «Татармультфильм» берләшмәсе генераль директоры Марат Ганиев та рәхмәтле.

– Татарстан Рәисе, ТР Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе һәм «Татнефть» компаниясе безнең канатларга көч-куәт бирделәр, бу зур эшне җиренә җиткерергә булышты. Аларның ышанычын акламый булмас. «Татнефть» компаниясе хезмәткәрләренә без мультфильмны Әлмәт шәһәрендә махсус күрсәттек. Нефтьчеләр безне бик җылы каршы алды. Алкышлары, рәхәтләнеп көлүләре, хисләнеп чыккан күз яшьләре өчен аерым рәхмәт, – диде ул.

Гомумән, «Татнефть» компаниясе белән хезмәттәшлекләре кичә-бүгенге генә түгел икән инде. «Без бергәләп уйлап тапкан Нефтяша тиене яшь тамашачыларга мультфильмнарда компаниянең экологик программасы, табигатьне саклау турында сөйли. «Нефтяша» дип аталган интернет-портал да булдырылды. Нефтьчеләр экология мәсьәләсенә һәрвакыт зур игътибар бирә», – диде Марат Ганиев.

«Татармультфильм» берләшмәсе пьеса сюжетын анимациягә күчерү турында күптәннән хыялланган. Иҗат берләшмәсенең баш режиссеры Сергей Киатров әйтүенчә (ул – бу мультфильмның режиссеры да. – **Авт.**), әлеге әсәргә алынулары юкка түгел.

– «Татармультфильм» берләшмәсе барлыкка килгән чорда, Туфан Миңнуллин безгә ярдәм итте, теләктәшлек күрсәтте. Аның әсәрләрен экранга чыгару турында күптәннән уйлана идек, – ди режиссер.

Аның сүзләренчә, «Әлмәндәр» нигезендә гади, тик бик мөһим кыйммәтләр дә ята. Шуңа ул тамашачы өчен тәрбияви яктан да кадерле. Шул рәвешле эчтәлеккә дә сак кагылганнар. «Биредә гаилә кыйммәтләре, тормышны ярату, халык зирәклеге һәм хәйләкәрлеге – барысы да бар. Без, бер караганда, барысын да пьесадагыча һәм

Илдар Мөхәммәтҗанов

спектакльдәгечә иттек. Әмма шул ук вакытта пьесадагыча да, спектакльдәгечә дә түгел. Алар бер-берсен кабатламый», – диде режиссер.

Мультфильмда татар мәдәнияте, татар халкына хас бизәкләр, төсләрне истә тотып эшләгәннәр. Сер итеп кенә әйтәбез: мультфильмны әзерләгән арада Сергей Киатров «Тартарика» дигән китапны да ятларга өлгергән инде.

> Танылган спектакльнең актерлар составы рәссамнар өчен илһам чыганагы булды. Безгә халыкның иң яраткан спектаклен яңа формаларда иҗат итү мөмкинлеге туды. Без бу әсәрне бүгенге һәм киләчәк буынга тапшырабыз. Ярдәм өчен Татарстан Рәисенә, ТР Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе җитәкчесе Марат Әхмәтовка, Мәдәният министрлыгына, «Татнефть» җәмгыятенә һәм шәхсән аның генераль директоры Наил Мәгановка рәхмәтләребезне җиткерәбез, – диде режиссер.

«Татармультфильм» студиясе җитәкчесе Азат Ганиев әйтүенчә, анимацион фильмны әзерләүгә ярты ел тирәсе вакыт киткән. Тагын берничә ай дәвамында студиядә иҗат җимешен тулы канлы мультфильм итү өчен тырышканнар.

– Без Әлмәндәр карт образын ачарга теләдек. Ул һаман да шул ук – балаларның өлкән дусты, Хәмдебану әбигә күз атучы, тормышны сөюче карт. Күңеле белән яшь ул, – диде Азат Ганиев.

Җан өрүчеләр

Әлмәндәр белән Әҗәлетдин алышын спектакль буларак караган буын мультфильмда да бу геройларның җанга якын тавыш белән сөйләшүен теләр иде, билгеле. Моңа ирешкәннәр дә. Билгеле, мәшһүр артистыбыз – Әлмәндәрне уйнаган Шәүкәт Биктимеров күптәннән гүр иясе. Геройны аңа охшатып Эмиль Талипов тавышландыра.

АНИМАЦИОН ФИЛЬМ ТУРЫНДА – САННАРДА

- Мультфильм **68** минут бара.
- Биредә **1126** күренеш, **650** рәсем, **26** музыкаль тема, **12** ария кулланыла.
- Мультфильмда барлыгы **90** персонаж.
- Иҗади эшне **96** кешедән торган төркем әзерләгән.

Аның каравы Әҗәл – безнең арада. Мультфильмда да күк канцеляриясе агентына данлыклы артистыбыз Равил Шәрәфиев үз тавышын «бирде».

– Мультфильмны тавышландыру тәкъдиме килгәч, дөресен әйтим, бик шикләндем. Бер үк елгага ике тапкыр керү, кабатлану булмасмы дип уйландым. Әмма бу – бөтенләй башка эш икән, без анимациягә яраклашырга тырыштык, – ди артист. – Спектакльдә дә, мультфильмда да әйтергә теләгән фикер шул ук дияргә була: Әҗәлдән куркырга кирәкми.

Равил ага мультфильмны ясаучы командага да рәхмәтле. «Алар бик вак эшне башкарып чыкты. Минем анимация тудырырга сабырлыгым җитмәс иде. Аны шулкадәр сәләтле, фантазиягә бай команда эшләде. Мин ул кешеләргә сокланам. Мультфильм яхшы килеп чыкса, ул – шушы команданың эше, начар икән, минеке дип санарсыз», – диде ул.

Зирәк картны тавышландырган Эмиль Талипов өчен дә мультфильмда катнашу яңа тәҗрибә булган. Әле эше дә җаваплы: ничәмә-ничә буын Әлмәндәрнең Шәүкәт ага тавышы белән «сөйләшүенә» күнеккән бит!

– Бу эшкә алынырга тәкъдим иткәндә, Шәүкәт абый шикеллерәк тавышландыра алмассыңмы дигәннәр иде. Әлмәндәр персонажын тавышландырганда күз алдымда Шәүкәт абыйны тоттым. Ул табигый да. Кеше дә шуны теләр иде. Бик үк аңа охшамаса да, тырыштык. Анимацион фильм спектакльгә нигезләнеп эшләнде. Тамашачының күз алдында барыбер спектакль торачак. Әмма мультфильмны спектакль турында онытып торып карарга кирәк, аларны чагыштырып булмый, – дип киңәш итә Камал театры артисты.

Эмиль Талипов мультфильмны, гомумән, иҗат берләшмәсе башкарган эшләрне татар телен популярлаштыруда да зур өлеш кертә дип саный.

– Татар телендә балаларына нәрсә күрсәтергә белмәгән ата-аналар өчен дә зур ярдәм бу. Кызымны үстергәндә, карарга бернәрсә дә юк иде. Ә мин аның теле татарча ачылуын теләдем. «Ютуб»та ни бар, җыеп күрсәттек, – диде ул.

Тамашаны карарга килгән Буа театры җитәкчесе Раил Садриев мондый мультфильмны дөньяга чыгаруны фидакарьлек дип атады.

– Бу күптәннән кирәк иде инде. Бу – зур эш. Моны айга менү белән чагыштырып булыр иде. Нил Армстронг әйткән бит: «Мин айга – бер адым, ә кешелек дөньясы зур бер сикереш ясады». Бу да – зур бер сикереш. Мультфильм, фильмнар белән болай да арттарак калдык без. Бездә мультфильм итәрлек темалар бихисап, – дигән фикердә ул. – Без бүген әллә нинди нәрсәләр күреп азып, иркәләнеп беткәнбез. Татарның бер сәгать буе бара торган һәм татар театрының төп әсәрләренең берсе булган пьесага нигезләнеп эшләнгән анимацион фильм алкышларга лаек. Тагын да күбрәк шундый иҗат җимешләрен чыгарырга кирәк.

«Әлмәндәр»гә озын гомер телик! Оештыручылар аны урыс теленә тәрҗемә итү турында да хыяллана. Димәк, татар картының зирәклеген тагын да күбрәк кеше күрәчәк.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5313 данә
Гомуми тираж – 14266 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 266

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+